Шигърият дөньясына сәяхәт : [«Адымнар-Чаллы» 59 нчы күп телләрне укыту гимназиясендә китапханәче, язучы Роза Хәмидуллина, шагыйрә, җырлар авторы Кәүсәрия Ямалиева һәм автор-башкаручы Зөлфия Җиһан белән очрашу] // Көмеш кыңгырау. – 2026. – № 17 (7 май). – Б. 2.



**«Адымнар-Чаллы» мәктәбендә язучылар белән очрашу циклының чираттагысы үтте. Ай саен үткәрелә торган мондый кичәләрдә Чаллы шәһәрендә каләм тибрәтүче, язучы һәм шагыйрьләр – «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары укучылар белән җанлы әңгәмә корды.**



# Шигърият дөньясына сәяхәт

Алдагы әңгәмәнең нәтиҗәсе буларак, 7А сыйныфы укучылары белән «Тукай эзләре буйлап» темасына конкурс үтте, презентацияләр һәм видеороликлар төшерү буенча урыннар билгеләнде.

«Шигырьнең җырга әверелүе» тематикасына багышланган әлеге кичәнең беренче кунагы – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы, шагыйрә, Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең әдәбият тарихы музее, «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе Роза Хәмидуллина иде.

Икенче кунагыбыз – «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, шагыйрә, җырлар авторы – Кәүсәрия Ямалиева.

Өченче кунагыбыз – «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, шагыйрә, автор-башкаручы – Зөлфия Җиһан чакырылган иде.

Укучылар кичәдә Кәүсәрия Ямалиева белән бергә шигырь язып карадылар. Шигырь язу бик җиңел түгел икән. Киләсе очрашу – 22нче май көнне Марс абый. Яһудин белән булачак. Гимназиябездә көтеп калабыз!

**7А сыйныфы укучылары,**
*«Адымнар-Чаллы» мәктәбе.*